**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 24 гыйнварындагы ПУ-44 номерлы, 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы, 2013 елның 10 августындагы ПУ-754 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы, 2014 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2014 елның 22 июлендәге ПУ-708 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 25 мартындагы ПУ-285 номерлы, 2016 елның 21 октябрендәге ПУ-950 номерлы, 2016 елның 26 ноябрендәге ПУ-1053 номерлы, 2017 елның 12 сентябрендәге ПУ-809 номерлы, 2017 елның 27 октябрендәге ПУ-976 номерлы, 2017 елның 25 декабрендәге ПУ-1156 номерлы һәм 2018 елның 14 февралендәге ПУ-165 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 кисәкне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«6 кисәк.**
**Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппаратында вазыйфалар исемлеге**

**1 бүлек. «Җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфалар**

**Иң югары төркем**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты идарәсе башлыгы | 06-1-1-01 |
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты бүлеге башлыгы | 06-1-1-02 |

**Баш вазыйфалар төркеме**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты идарәсе башлыгы**** | 06-1-2-03 |
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты бүлеге башлыгы**** | 06-1-2-04 |

**Әйдәүче вазыйфалар төркеме**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы матбугат секретаре | 06-1-3-05 |
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты секторы мөдире | 06-1-3-06 |

**2 бүлек. «Ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге вазыйфалар**

**Баш вазыйфалар төркеме**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе киңәшчесе | 06-2-2-07 |

**3 бүлек. «Белгечләр» категориясендәге вазыйфалар**

**Баш вазыйфалар төркеме**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 06-3-2-08 |
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты бүлеге составындагы сектор мөдире | 06-3-2-09 |

Баш инспектор 06-3-2-10

Әйдәүче киңәшче 06-3-2-11

**Әйдәүче вазыйфалар төркеме**

Әйдәүче инспектор 06-3-3-12

Әйдәүче консультант 06-3-3-13

**4 бүлек. «Тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфалар**

**Баш вазыйфалар төркеме**

Баш белгеч 06-4-2-14

**Әйдәүче вазыйфалар төркеме**

Әйдәүче белгеч 06-4-3-15

**Өлкән вазыйфалар төркеме**

1 разрядлы өлкән белгеч 06-4-4-16»;

б) «****» символы белән билгеләнгән астөшермәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының, Татарстан Республикасы Хисап палатасының эшчәнлеген мәгълүмати-техник, документлар белән, финанс-икътисадый тәэмин итүне гамәлгә ашыручы идарә, бүлек башлыклары вазыйфалары.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 04 август
№ ПУ-549